КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 июнь г.Казань № 489

Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренә ярдәм чаралары турында

Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренә ярдәм чаралары күрсәтү һәм Татарстан Республикасы мәдәният тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Анда килүчеләргә рөхсәт туктатылган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына агымдагы финанс елында аерым дәүләт хезмәтенә (эшләргә) карата сыйфат күрсәткечләренең һәм (яисә) күләмнең билгеләнгән зурлыкларыннан процентларда (абсолют зурлыкларда) рөхсәт ителгән (мөмкин) тайпылышларны үзгәртү рөхсәт итәргә.

2. Буге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин